ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.10.2019 Алексеевск ш. т. б. № 456

**Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
“Советлар Союзы Герое Иван
Егорович Кочнев исемендәге2 нче
Алексеевск урта гомуми белем
бирү мәктәбе”муниципаль бюджет
гомуми белем бирү
учреждениесендә түләүле белем
бирү хезмәтләре күрсәтү турында**

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы карамагындагы дәүләт бюджет учреждениеләре эшчәнлегенең төп төрләренә караган хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) түләүне билгеләүнең гражданнар һәм юридик затлар өчен якынча тәртибен раслау турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 30 декабрендәге 1170 номерлы карары нигезендә (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән),Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) белем бирү оешмалары тарафыннан физик (юридик) затларга күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында регламентны раслау хакында” 2014 елның 6 маендагы 2556/14 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы “Советлар Союзы Герое Иван Егорович Кочнев исемендәге 2 нче Алексеевск урта гомуми белем бирү мәктәбе " муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең матди-техник базасын ныгыту максатларында

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының “Советлар Союзы Герое Иван Егорович Кочнев исемендәге 2 нче Алексеевск урта гомуми белем бирү мәктәбе " муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтүне оештырырга.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының “Советлар Союзы Герое Иван Егорович Кочнев исемендәге 2 нче Алексеевск урта гомуми белем бирү мәктәбе "муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтүгә бәяләр исемлеген һәм прейскурантын расларга (Кушымта).

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының "Бюджет һәм Автоном учреждениеләренең бюджеттан тыш чаралары турында" 2016 ел, 30 декабрь, 21-53-24-3742 нче хаты нигезендә түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган акчаларны тоту тәртибен билгеләргә:

- матди-техник базаны ныгытуга чыгымнар - 25%

- хезмәт өчен түләү билгеләү һәм хезмәт өчен түләү чыгымнары - 75%,

4.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының “Советлар Союзы Герое Иван Егорович Кочнев исемендәге 2 нче Алексеевск урта гомуми белем бирү мәктәбе”муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директорына (Липлянина Л.Н.):

- гамәлдәге законнар нигезендә түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү өчен шартлар тудырырга.;

- түләүле белем бирү хезмәтләре турында мәгълүматны мәгариф оешмасының рәсми сайтында һәм мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

6.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Н.П.Чуринга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
02.10.2019ел № 456лы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы “Советлар Союзы Герое Иван Егорович Кочнев исемендәге 2 нче Алексеевск урта гомуми белем бирү мәктәбе”муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә түләүле белем бирү хезмәтләре исемлеге**

| № т/б | Хезмәтнең атамасы | Хезмәтләр саны/озынлыгы, мин. | Бәясе хезмәтләр аена (сумнарда) |
|---|---|---|---|
| 1 | “Әлифба юлында” балаларны укуга һәм язуга өйрәтүгә практик әзерлек» | Атнага 2 тапкыр/ 30 мин. | 200 |
| 2 | “ Математика баскычлары” башлангыч математик күзаллауларны формалаштыру. | Атнага 2 тапкыр/ 30 мин. | 200 |
| 3 | "Бәхетле Инглиз теле» | Атнага 2 тапкыр/ 30 мин. | 200 |
| 4 | Гади хореографик хәрәкәтләргә өйрәтү "Step-аэробика. BasicStep” | Атнага 1 тапкыр/ 30 мин. | 100 |
| 5 | Логопед-педагогның шәхси консультациясе | 1 тапкыр/30 мин. | 300 |
| 6 | Сөйләм үсешен коррекцияләү буенча педагог – логопед белән индивидуаль дәресләр. | Атнага 2 тапкырдан да ким түгел/ 30 мин. | 200 |
| 7 | Вак моториканы үстерү, “Тестопластика” әвәләп ясау техникасы белән шөгыльләнү аша. | Атнага 1 тапкыр/ 30 мин. | 100 |

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г. А. Йосыпова**